Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFӨNYN
УНИВЕРСИТЕТ

12+

№3 (54)

31 гыйнвар 2013 ел

## • Универ хәлләре

**«ТАТЬЯНА КӨНЕ» БӘЙРӘМЕНДӘ РЕКТОР ИЛШАТ ГАФУРОВ СТУДЕНТЛАР БЕЛӘН АРАЛАШТЫ.** Күрешүдә университетның иҗтимагый-актив яшьләре, РФ Фән һәм Мәгариф министрлыгының Балаларга өстәмә белем бирү, тәрбияләү һәм яшьләр сәясәте департаменты директоры Александр Страдзе, ТРның яшьләр, спорт һәм туризм министры урынбасары Рөстәм Гарифуллин катнашты. Илшат Гафуров, студентларның тәкъдимнәрен тыңлаганнан соң, комментарийларын әйтте. Төп проектлар, үсеш-үзгәрешнең приоритет юнәлешләре белән таныштыргач, ректор Универсиада Авылында хоккей тартмасын, КФУ сайтының инглиз телендәге аналогын булдырырга, студентларның иҗатларын үстерүгә булышлык итәргә сүз бирде.

• • • •

Шул ук көнне Казан федераль университетының ИТ-лицеенда **РЕСПУБЛИКА ЯШЬЛӘР ФОРУМЫ-2012 ИҢ ЯХШЫ ПРОЕКТЛАРЫ ПРЕЗЕНТАЦИЯСЕ БУЛДЫ.** Чарада, традиция буенча, Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миннеханов та катнашты. Барысы 1044 гариза бирелгән, күргәзмәдә 9 тематик мәйданда шуларның 60ы тәкъдим ителде. «Яшьләр фәне һәм инновацияләр» мәйданында Рамил Кашапов тәкъдим иткән Казан федераль университеты һәм Е.К.Завойский ис. Казан физика-техника институты РФАның Казан фәнни үзәгенең «3D-принтер» уртак проекты җиңү яулады.

• • • •

**26 ГЫЙНВАРДА** Казан университеты УНИКС концертлар залында **СТУДЕНТЛАР КӨНЕН БӘЙРӘМ ИТТЕ.** Тантананы ректор Илшат Гафуров башлап җибәрде. Чарада концерт номерларыннан кала, «Идел буе Татьянасы-2013» түбәкара фестиваленә нәтиҗәләр ясалды. Җиңүче итеп, Н.П.Огарев ис. Мордва дәүләт университетыннан Татьяна Дудникова танылды. «Голос» проектында җиңгән КФУ студенты Динә Гарипова да үзенең бер җырын бүләк итте.

• • • •

Педагогика һәм психология институты делегациясе Эль-Пасодагы Техас Университетына (АКШ) визиты вакытында **КФУ ҺӘМ ЭПТУ АРАСЫНДА ХЕЗМӘТТӘШЛЕККӘ КУЛ КУЕЛДЫ.** Техас университеты җитәкчелеге һәм хезмәткәрләре белән эшлекле очрашу вакытында, уку йортларыбызның педагогика һәм психология өлкәсендә төп юнәлешләре билгеләнде.

• • • •

**28 ГЫЙНВАР КӨННЕ** Казан университетында Казанның **ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ УЧРЕЖДЕНИЕ ҖИТӘКЧЕЛӘРЕНЕҢ БЕЛЕМНӘРЕН КҮТӘРҮ КУРСЛАРЫ БАШЛАНДЫ.** Чара №261-ФЗ «Энергияне саклау һәм энергетик эффектлылыкны арттыру, РФның аерым закон актына үзгәрешләр кертү турында» Федераль закон нигезләмәсен аңлатуга багышланды.

• • • •

**28 ГЫЙНВАРДА** Илшат Гафуров җитәкчелегендә **РЕКТОРАТНЫҢ ЧИРАТТАГЫ УТЫРЫШЫ БУЛДЫ.** Беренче булып, ректор профсоюз оешмасының яңа җитәкчесе һәм II профсоюз җыелышы нәтиҗәләре белән таныштырды. Аннары, гадәттәгечә, административ эшләр буенча проректор, аппарат җитәкчесе **АНДРЕЙ ХАШОВ** контроль йөкләмәләрнең үтәлеше һәм атна дәвамында узачак вакыйгалар турында сөйләде. Икътисади һәм стратегик эшләр буенча проректор **МАРАТ САФИУЛЛИН** Казан федераль университетының 2012 елдагы Үсеш программасы нәтиҗәләре белән таныштырды. Финанс эшләре буенча проректор **РӘЙСӘ МУЛЛАКАЕВА** түләүле белем бирү хезмәте күрсәткән, дәүләт үрнәгендәге диплом тапшырган өчен кергән акчаларны КФУның үзәкләштерелгән матди базасына күчерү турында мәгълүмат бирде. 2012 елның 1 гыйнварыннан алып, 2013 елның 1 гыйнварына кадәр булган вакыт аралыгында федераль университет милкен рәсмиләштерү турындагы законның үтәлешен тикшерү буенча проректор **МАРАТ САФИУЛЛИН** сөйләде. Тышкы элемтәләр департаменты директоры **АНДРЕЙ КРЫЛОВ** сайтның инглиз телендәге эшләнеш халәте белән таныштырды. Ахырдан Хисаплау математикасы һәм мәгълүмати технологияләр институты директоры **РӨСТӘМ ЛАТЫЙПОВ** институт структурасына кертелгән үзгәрешләр турында әйтте.

*kpfu.ru сайты материаллары файдаланылды.*




*Фотода «Ел студенты-2012» бәйгесе җиңүчеләре: «Darelfønyn» коллективы һәм К. Кадочникова*

Эмир Фазлыйәхмәтов фотосы

# Тәүге җиңү

**Алинә САДЫЙКОВА,** хәбәрче

«Ел студенты-2012» бәйгесен бөтен «Darelfønyn»енебез белән бик зарыгып һәм түземсезлек белән көттек. Сәбәбе дә бар бит: «Елның иң яхшы массакүләм мәгълүмат чарасы» номинациясенә кертелдек. Алай гына түгел, беренчелекне дә без алдык. Тулы горурлык белән әйтә алабыз: 2012 елда без – иң яхшылары!

Җиңү җиңел генә бирелмәде: бәйгедә катнашу өчен Татарстан республикасының югары уку йорты һәм махсус урта белем бирү йортларыннан 380нән артык гариза бирелгән. Жюри шулар арасыннан 17 номинациягә лаек булырдай иң-иңнәрне сайлады.

Бәйгедә КФУдан 7 номинациядә 7 кеше һәм 3 коллектив катнашты. Нәтиҗәләр 25 гыйнвар көнне «Пирамида» мәдәни-күңел ачу комплексында игълан ителде.

Тантана бик дустанә һәм җылы атмосферада узды. Моның өчен оештыручыларга аерым рәхмәт әйтергә кирәк. Югары дәрәҗәдәге концерт номерлары, иганәчеләр әзерләгән кыйммәтле бүләкләр, җиңүчеләрне котларга килгән дөньякүләм танылган кунаклар һәм, әлбәттә, яшьләрнең яхшы, күтәренке кәефе бу бәйрәмне онытылмаслык итте.

Безнең өчен иң истә калачак мизгел: үзебезнең номинациядә җиңүчене игълан итү вакыты. Аны сүз белән әйтеп һәм язып кына бетереп булмый. Шатлану, горурлану, сөенү бергә катнашканнан соң, хисләребез әкрен сыймый башлады. Әле елыйсы, әле көләсе, әле берәрсен кочаклап кычкырасы килде. Чынбарлыкка ышану өчен бераз вакыт кирәк булды, чөнки көндәшләребез чыннан да бик көчле иде. Шулай да без алардан өстен булып чыктык! Газетабызның җиңүе – сайлаган һөнәребезне ярату, күңел биреп эшләү һәм үзара дус-тату булуның нәтиҗәсе! Бу – иң мөһим, иң горурланырлык җиңүебез һәм ул соңгысы булмас дип ышанабыз.

Университетның Массакүләм коммуникацияләр һәм социаль фәннәр институты студенты Ксения Кадочникова «Ел журналисты» номинациясендә җиңүче булды. Аны да тәбрик итәбез һәм иҗат уңышлары телибез!

## • Киңәшмә

# Уку йортлары якыная

**Динара МИННЕКАЕВА,** хәбәрче

29 гыйнвар көнне Татарстан Республикасының югары уку йортлары ректорлары Советы утырышы булды.



Руслан Гыйниятов фотосы

Җыелышны сәламләү сүзе белән ректорлар Советы рәисе, КФУ ректоры Илшат Гафуров һәм ТРның төп федераль инспекторы Рөстәм Идрисов башлап җибәрде.

Көн тәртибенә куелган беренче мәсьәлә ТР вузлары студентлары арасында ислам экстремизмына каршы көрәш эшчәнлеге барышы темасына багышланды. Россия эчке эшләр министрлыгының Казан юридик институты җитәкчесе, полиция генерал-майоры Фоат Зиннуров бу уңайдан бик актуаль проблемаларны күтәрде.

**Ахыры 2нче биттә.**

• Галимнәребез

# Нобель укытучысы

**Зилә ФӘСХИЕВА,**
хәбәрче

29 гыйнвар көнне Казан федераль университетының актлар залында «Синтез, төзелеш, органик, элементоорганик һәм координацион бәйләнешләрнең тәэсир итү мөмкинлекләре һәм гамәли яктан әһәмияте» дип исемләнгән фәнни-гамәли конференция үтте. Ул Н.Н.Зининның тууына 200 ел тулуга багышланды.





Наилә Бадыкшанова фотолары

Тантаналы утырышны КФУ ректоры Илшат Гафуров ачып җибәрде. Ректор Н.Н.Зинин кебек шәхесләрнең фәнни тәгълиматына нигезләнеп үсә торган Казан химия мәктәбенә өметләрнең зур булуын әйтте, ә катнашучыларга исә яхшы кәеф һәм чыгышлардан яңа мәгълүматлар алуларын теләде.

Чарада Татарстанның фәнни-химик берләшмә вәкилләре дә катнашты. Алар да Казан химия мәктәбенең үсешендә Зинин эшчәнлегенең зур роль уйнавына басым ясады. Россия Фәннәр Академиясе химия бүлеге әгъзасы Олег Синяшин үзенең чыгышында яшь белгечләрне химия белән кызыксындырып җибәрүнең үзенчәлекле юлларын күрсәтте: «Бу бөек исем ике шәһәребез - Казан белән Санкт-Петербургны бәйләп тора. Ә Казан химия мәктәбе, миңа калса, үзенең билгеле шәхесләрен танытуга игътибарны арттырырга тиеш. Мәсәлән, Бутлеров укулары исемле чара яки исемле медальләр бирүне оештырып җибәрергә кирәк».

Вильям Барабанов үз чыгышында Н.Н.Зинин эшчәнлеге белән бәйләнеше темасын күтәрде. Дөрестән дә, XX гасырның беренче яртысында эшчәнлек алып барган галимнәрнең барысы да диярлек Зинин укучылары булган. Нәтиҗәдә, тагын бер талантлы химиклар буыны үсеп чыккан.

Конференциянең беренче өлешендә тарихи бәйләнешләр турындагы докладларга өстенлек бирелсә, алга таба тагын да үзенчәлеклерәк чыгышлар яңгырады. Мәсәлән, Бутлеров исемендәге химия институты органик химия кафедрасы мөдире Игорь Антипин КФУдагы органик химия буенча эшчәнлеккә күзәтү ясады. Казан химия мәктәбе музее хезмәткәре Зининның тормыш юлы һәм фәнни эшчәнлеге турында тулы мәгълүмат җиткерде.

Николай Зинин исеме Казан һәм Казан университеты белән тыгыз бәйләнгән. Саратов гимназиясен алтын медальгә бетереп, ятим, Казанда яшәү өчен беринди мөмкинекләре дә булмаган яшь малай Казан университетына укырга килә. 1833 елда Казан император университетының физика-математика бүлеген бик яхшы билгеләргә тәмамлый. 1835 елда университетта химия фәнен укыта башлый. Тагын ике елдан Германиягә стажировкага җибәрелә һәм бер ел дәвамында Ю.Либихның химия лабораториясендә эшли. Казанга кайткач, шушы эшчәнлекне дәвам итеп, органик химия курсларын укыта башлый. Мавыктыргыч лекцияләре, кызыклы гамәли дәресләре белән лабораториягә күп студентларны җәлеп итә. Педагогик эшчәнлек белән фәнни тикшеренүләрне берләштереп, зур уңышларга ирешә.

1842 елда бер реакцияне (Зинин реакциясе) ача. Аның ярдәмендә лаборатор шартларда синтетик анилин табыла. Ул натураль сыйфатларга ия була. Бу ачыш Зининны һәм Казан университетын бөтен дөньяга таныта. Унбиш елдан соң, реакция заводларга күчерелә һәм фармацевтика сәнәгатенә нигез салына. 1847 елда галим Петербург Медицина-хирургия академиясенең химия кафедрасына профессор итеп сайлана. Рус химия җәмгыятен төзүчеләрнең берсе буларак, ун ел дәвамында аның президенты итеп сайлана.

Николай Зинин исеме һәр елны Стокгольм Концерт залында Нобель комитеты рәисенең Нобель премияләрен тапшырыр алдыннан сәламләү сүзендә яңгырый. Бу бер дә юкка түгел, чөнки А.Нобель Н.Зининны үзенең укытучысы дип санаган. Ә Казан университеты галиме аңа бик күп тапкыр дәресләр биргән.

• Киңәшмә

# Уку йортлары якыная

*Башы 1нче биттә.*

Экстремизм җәмгыятьнең күп өлкәләренә үтеп керде. Соңгы араларада җөмһүриятебездә булган криминаль вакыйгалар аерууча борчуга сала. Иң куркынычы: яшь буын шундый тискәре хәлләрне үзенә сеңдереп бара. Бүгенге көндә Россия Федерациясендә экстремистик юнәлештәге 100 төркем бар. Алар якынча ярты миллион яшь кешене берләштерә. Мондый күренешләрнең күбәюенә төрле факторлар сәбәп булырга мөмкин. Әйтик, эшсезлек, кешене хезмәт хакына карап бүлү, милләтара конфликтлар, дәүләт җитәкчеләренә ышанмау һ.б.

Терроризм һәм экстремизмны юкка чыгару өчен, бик күп эшләр башкарылса да, әле камиллеккә ирешеп булмый. Фоат Зиннуров, югары уку йортлары эшчәнлегенә анализ ясаганда, Казан федераль университеты эшчәнлегенә аерым тукталды. КФУда бу проблема белән көрәшү өчен конкрет программа булдырылган. «Җәйге Универсиада барышында мондый күңелсез хәлләр килеп чыкмасын өчен күп көч куярга кирәк. Яшәү белән үлем турында сүз барганда, беркем дә битараф калырга тиеш түгел», – дип чыгышын төгәлләде.

Утырышта шулай ук ТРның Гуманитар фәннәр буенча вузара координацион советы турында нигезләмә расланды. Координацион совет вузларны үзара якынайту, мәгълүмат һәм тәҗрибә уртаклашу максатыннан булдырылды. Аның рәисе итеп, сәяси фәннәр докторы, профессор, КФУның Массакүләм коммуникацияләр һәм социаль фәннәр институты директоры Наил Мөхәрәмов билгеләнде.

Ректорлар Советы составына да үзгәрешләр керде. Кама дәүләт инженерия-икътисад академиясенең (ИНЕКА) КФУ составына кушылуы аркасында, аның ректоры Владимир Шибаков, шул ук вуз президенты Асфандияр Хәйруллин составтан чыгарылды. Ә Социаль белем бирү академиясе ректоры Искәндәр Мөхәммәтҗанов Ректорлар советына кабул ителде.

Балалар йортында тәрбияләнгәннәргә югары уку йортында да махсус шартлар тудырылырга тиеш. Бу теманы «ТИСБИ» Идарә итү университеты ректоры Нелла Прусс күтәрде. Шәхес тәрбияләү, иң мөһиме, җаваплылык, креативлык, мөстәкыйльлек, башкаларга хөрмәт белән карау кебек сыйфатларны булдыру һәр уку йортының төп максаты булып тора. Аның гуманитармы, техникмы икәне мөһим түгел. Н.Прусс сүзләренчә, сәламәтлек ягыннан зәгыйфь студентлар алдында Казанда яшәү урыны булмау төп проблема булып тора. Бу мәсьәләне чишү юлы бар: аның өчен махсус Адаптация үзәге булдырыга кирәк.

Алдагы сорау да студентларның адаптациясенә бәйле булды. Ноябрь аенда Татарстан Республикасының VII студентлар Конгрессы барышында Президентыбыз Рөстәм Миннеханов вуз җитәкчеләре алдына 10 февральгә кадәр чит ил студентлары белән эшләү Концепциясен булдыру бурычын куйды.

Җәйге Универсиадага бәйле һәр мәсьәлә бүген бик актуаль. Июль аенда узачак спорт ярышлары вакытында Казан шәһәре югары уку йортларының тулай тораклары Универсиада объектлары фондына биреләчәк.

Быел совет гаскәрләренең фашистларны Сталининград сугышында юк итүләренә 70 ел тула. Бу уңайдан Россия ректорлар союзы мөрәҗәгате каралды. 2012 елның декабреннән башлап, 2013 елның февраль аена кадәр, «Сталининград дәресләре» дигән ачык лекцияләр циклы үтәргә тиеш. Иң яхшы лекцияләр видеоязмасы Россия ректорлары союзы сайтында махсус бүлектә урын алачак. Шулай ук 2013 елның 1 маена кадәр 2013/2014 уку елы программасына «Икътисад, сәүдә сәясәте һәм Бөтендөнья сәүдә оешмалары хокукы, Таможня союзы һәм БДБ илләренең ирекле сәүдә зонасы» махсус курслары кертү проекты каралырга тиеш. Бу Премьер-министр Илдар Халиков боерыгы буенча эшләнә.

Якын киләчәктә А.Н.Туполев ис. Казан милли тикшеренү техник университетына ректор сайлаулары үтәчәк. Биредә өч кандидат бар. Алар – Владимир Гайнутдинов, Илгиз Гафиятов, Альберт Гыйльметдинов. Әлеге кандидатлар да бер тавыштан расланды.

• Җуелмас байлык



# «Е» һәм Казан университеты

**Алинә Садыйкова,** хәбәрче

Узган саннарның берсендә Василий Савельев истәлегенә багышланган кичә турында язган идек. Ул Казан университеты, аның бинарлары, төзелеш принциплары турында «Җуелмас байлык» альбом-китабын әзерли башлаган. Әмма аның вакытсыз бакый дөньяга күчүе аркасында, бу эшне хатыны дәвам итеп бетерә. Әлеге китапны, чын мәгънәсендә, хәзинә дип атап була. Шуңа күрә без сезне дә алга таба аның эчтәлеге белән таныштырып барырга уйладык. Бу санда исә уку йортыбызның тарихына күз салыйк.

Һәркемгә билгеле: 1804 елның 5 ноябрендә Александр I Казан император университетын булдыру турындагы Раслау Грамотасы һәм Уставына кул куя. Университетыбызны бүген дә шул чор модасын, гадәтләрен, стилен саклап калган һәм шуңа ишарәләп тора торган һәйкәл дип атасак та була. Монда барлык дәверләр өчен мөһим һәм аңлаешлы тәртип, гармония, кырыс матурлык сакланган.

1800-1812 еллар дәвамында, Александр классицизмы архитектурасы – соңгы классицизм һәм аның чәчәк атуы – бик популярлаша. Бу стильнең формалашуына борынгы грек архитектурасы йогынты ясый. XIX гасыр «Сугышка кадәрге» архитектура стиленең үзенчәлекләре Александр I идеяләре һәм эшчәнлеге белән тәңгәл килә. Александрның идарә итү формасы һәм сәяси идеяләре империяле Рим белән түгел, ә Перикл чорының демократик Афина иҗат формасы белән аваздаш булган. Элегрәк киң таралыш алган Коринф урынына, Пестундагы Посейдон храмының куәтле һәм төз Дорийда ордены колонналары модага керә башлый. Үзгәреш җилләре Казанны да читләтеп узмый.







Күренекле архитекторлар П.Г.Пятницкий һәм М.П.Коринфский (чын фамилиясе – Варенцов) Россиянең иң яхшы һәйкәлләренең берсен – Казан университеты ансамблен булдыралар. Университет шәһәрчеген барлыкка китерүдә зур рольне төзүчеләр комитеты рәисе Н.И.Лобачевский башкара. Пятницкий университет бинарлары ансамбленең гомуми планировкасын эшли, төп бинаның проектын һәм үзен төзи, ә Коринфский, элгәренең генпланына төзәтмәләр кертеп, башка бинарларны тергезә. Биектән караганда, төп бина, Александр I хыялланганча, «Е» хәрефенә охшаган. Бу аның әбисе - Екатерина II - истәлегенә бәйле.

● Ана теле

# Хыянәтме? Әллә...

**Алинә БӘДРЕТДИНОВА,**
татар филологиясе бүлеге

КЫШНЫҢ БЕР КӨНЕ. САЛМАК КЫНА ТИРБӘЛЕП, ҖИРГӘ ЭНҖЕДӘЙ КАР БӨРТЕКЛӘРЕ ТӨШӘ. АКЛЫККА ТӨРЕНГӘН ДӨНЬЯНЫҢ ИЛАҺИ САФЛЫГЫНА СОКЛАНЫП, АКРЫН ГЫНА АТЛЫЙМ. ТИРӘ-ЮНЬ СИХРИ ТЫНЛЫККА ЧУМГАН, БАРЫ ТИК АЯК АСТЫНДАГЫ КАРНЫҢ КҮҢЕЛЛЕ АВАЗЛАР ЧЫГАРЫП ШЫГЫРДАВЫ ГЫНА ИШЕТЕЛӘ. МИҢА ШУНДЫЙ РӘХӘТ: МЕНӘ-МЕНӘ КАНАТЛАНЫРМЫН ДА АП-АК ЧИКСЕЗЛЕККӘ ОЧЫП КИТӘРМЕН КЕБЕК. Ә БАШЫМДА МЕҢ ТӨРЛЕ УЙ, МЕҢ ТӨРЛЕ ХЫЯЛ...

Нәкъ менә бөтен дөнья аклыкка төренгән кышкы көндә Казан Федераль Университеты ишекләрен ачып керү бәхетенә ирештем. Ә бу хакта мин күпме хыялланган идем бит?! Менә хыялымдагы татар филологиясе факультеты... Якташым Рифә Рахман оештырган «Саф чишмәләр» иҗади эшләр бәйгесендә җиңү яулавым бу факультетка карата кызыксынуны арттырды. Шуннан соң: «һичшиксез, әлеге бүлекнең алдынгы студенты булырга тиешмен», – дигән олы максат куйдым.

Әйе, моңа кадәр дә туган телебезгә карата битараф түгел идем. Саф татар гимназиясендә уку дәверендә үк җаныма, рухыма татар мохите кергән һәм киләчәктә милләтемә намус белән хезмәт итүче дәүләт эшлеклесе булачагымны аңладым.

Эш синең нинди факультетны бетерүеңә бәйле дип санамыйм. Иң мөһиме: ныклы белемле, тырыш, кыю, үҗәт холыклы булырга кирәк. Татар теле белән беррәттән, рус, инглиз телләрен дә яхшы белү миңа илебезнең киләчәге өчен көрәшүдә ярдәм итәчәк. Татарлар яши торган теләсә кайсы төбәккә барып, зур киңәшмәләрдә, утырышларда рәхәтләнеп туган телемдә аралаша алачакмын. Дәүләт эшлеклесе буларак, милләтнең бетүенә, кыерсытылуына юл куймаячакмын, киресенчә, депутатлар белән киңәшеп, халкым өчен зур мөмкинлекләр тудырачакмын.






*Эш синең нинди факультетны бетерүеңә бәйле дип санамыйм. Иң мөһиме: ныклы белемле, тырыш, кыю, үҗәт холыклы булырга кирәк. Татар теле белән беррәттән, рус, инглиз телләрен дә яхшы белү миңа илебезнең киләчәге өчен көрәшүдә ярдәм итәчәк.*

Бүгенге көндә актуаль проблемаларның берсе: милли белем бирү белән бәйле мәсьәләләр, төгәл генә әйткәндә, мәктәпләрдә ана теленә карата кызыксыну кимү, туган телне җиренә җиткереп өйрәнү өчен уку китаплары җитмәү һ.б. Милли белем бирү учреждениеләренең кимүенә йогынты ясый торган факторлар булып, демографик вәзгыять, бердәм дәүләт имтиханын бары тик рус телендә генә бирү тора. Шулай да республикада милли телләрне үстерүгә зур көч куярга кирәк дип саныйм. Минемчә, баланы мәктәпкәчә белем бирү оешмаларына ясарга кирәк. Телне шул чорда үзләштереп, өйрәнеп калсаң гына, ул мәңге истә кала.

Бүгенге көндә тамырына балта чабылып, бетерелүгә барган татар авыл мәктәпләренең киләчәген кайгыртып, милли рухта тәрбияләүче, ана теленә мәхәббәт уята белүче укытучылар өчен җан атып эшләячәкмен.

Милләтебезнең үсешен таркаулык мәсьәләсе дә тоткарлый. Без үзебезне татарга, мишәргә, нугайга, типтәргә, керәшенгә, Әстерхан, Себер, Кырым татарларына бүлгәләп бетердек. Башка милләтләрдә, әйтик, урысларда мондый бүленешне ишеткәнем юк. Халык санын алу вакытында да Мәскәү моны үз файдасына борды. «Аерылганны аю ашар, бүленгәнне бүре ашар» мәкален дә үзебезгә карата әйткәнбез булып чыга түгелме? Татар кешесе үзен керәшен, мишәр, типтәр дип атаса да, яшәве Себердә яки Әстерханда булса да, ТАТАР дигән зур, көчле, гайрәтле кавемнең бер баласы икәнен онытмаска тиеш.

Саный китсәң, татар теленең бетә баруын аңлату өчен бик күп сәбәпләр табарга мөмкин. Бу проблема беркем өчен дә яңалык түгел һәм инде бик күп еллар татар дөньясында иң кискен мәсьәлә булып санала. Ирексездән сорау туа: ә аны хәл итеп буламы соң? Өметсез – шайтан, диләр.

Кайбер маңкорт җанлы кешеләрдән еш кына: «Нигә соң ул татар теле? Ындыр артына чыгуга кирәге бетә бит аның», – дигән сүзләрне ишетергә туры килә. Ләкин... Кошлар, хайваннар да үз телләренә хыянәт итмиләр. Чыпчык та сандугач булып сайрамый бит.

● Тарих сәхифәләреннән




*1923 ел*
☛**30 гыйнвар** – Мәгариф союзы эшчеләре күрсәтмәләре нигезендә Университетта эшчеләрнең профсоюз ячейкасы оешкан. Шул ук вакытта белгечлекләр буенча 14 секция эшли башлаган.

*1943 ел*
☛**3 февраль** – Университетның партия бюросында Казан университетының фронтка мобилизацияләнгән хезмәткәрләре һәм студентларның гаиләләренә ярдәм күрсәтү турындагы мәсьәлә каралган. Шул ук айны партбюро тарафыннан фронтовик гаиләләренең хәлен тикшерү турында отчет тыңланган.

*1963 ел*
☛**29 гыйнвар** – РСФСР Югары һәм махсус урта белем бирү министрлыгы Казан Университетын табигатьне үзгәртү, тикшерү эшләрендә табигый ресурсларны комплекслы куллану проблемасы эшкәртмәсен һәм «Урта Идел икътисади районының табигый ресурслары һәм табигый шартлар атласы»н булдыруда катнашырга өндәгән. Ректор приказы буенча, әлеге атласны ясау физика географиясе кафедрасына йөкләнә. Эшнең фәнни җитәкчесе итеп профессор А.В. Ступишин билгеләнә.

☛**30 гыйнвар** – СССР югары һәм махсус урта белем бирү министрлыгы приказы буенча, югары уку йортларында һәм фәннитикшеренү учреждениеләре каршында стажер-тикшерүчеләр турындагы Нигезләмә раслана.

*2003 ел*
☛**28 гыйнвар** – Ректор приказы белән, КФУның 2003 елның 23 гыйнвар көнге Гыйльми советы карары нигезендә, структур бүлекчәләр Гыйльми советларының якынча нигезләмәсе расланган.

☛**1 февраль** – «Киләчәк буын фондын булдыру» коммерцияле булмаган оешма директоры Н.Г. Забиров һәм Казан Дәүләт Университеты ректоры М.Салахов килешү төзегәннәр. Әлеге килешү буенча, Фонд Казан университетының табигый фәннәр факультетларында укучы студентларга 10 махсус стипендия түләр өчен 57500 сум акча бүлеп биргән.

● Киңәш-табыш

# Экваторга җиттек!

**Динара МИННЕКАЕВА,**
хәбәрче

Экватор... Синең дә күз алдыңа мәктәп елларындагы география фәне килдеме? Зур карта эленгән такта алдында укытучы нидер аңлата. Мин дә, студент булганчы, бу сүзнең бер генә мәгънәсен аңлый идем. Алай гына да түгел, әле беренче курста укыганда да өлкәнрәк студентларның бу турыда сөйләшкәннәрен ишетсәм, аптырап калган чаклар булды. Кызык, хәзер экватор дигән саен, бер дә Җир шарын икегә бүлә торган сызык түгел, ә үземнең студент еллары искә төшә.

Әйе, әйе, безнең дә булды экватор. Кемнәрдер коттеджда бәйрәм итте, кемнәрдер кафеда күңел ачты, кемнәрдер боулинг, бильярд уйнады. Ә без төркем белән җыелдык та туган авылыма кайтып киттек. Якын ара түгел, иртәнге электричкада юлга кузгалдык. Ап-ак карга чумган агачлар да, йокыларыннан уянып, безне озатып калды. Киров өлкәсен, Удмуртиянең берничә шәһәрен артта калдырып, җөмһүриятебезнең иң ерак районына кайтып җиттек. Шатлыгыбыз эчкә сыймый, хәтта көннең ни дәрәҗәдә салкын икәне дә сизелмәде. Ничек күңел ачканыбыз беркемгә дә кызык түгелдер дип уйлыйм, иң мөһиме: гомер буена истә калырлык бәйрәм булды.

Ә нәрсә соң ул «студентлар экваторы»? Студентлар телендә ул укуның уртасында (3 курста кышкы сессияне тапшыргач) үткәрелә торган рәсми булмаган бәйрәм. Шуннан соң студент тормышының икенче өлеше: тагын да күңелле, шул ук вакытта мәшәкатьле чоры башлана.

Әлеге бәйрәмнең тамырлары диңгезчеләр традициясенә барып тоташа. Диңгезчеләрдә экватор кисешүен бәйрәм итә торган гадәт бар икән. Мондый тарихи вакыйга истә калсын өчен, алар диңгезгә сикерә. Ләкин студентларга болай эшләргә кирәкми, алар инде болай да биш ел белем диңгезеннән чыкмый.

Шулай да, студентлар арасында бу бәйрәмне зурлап үткәрүчеләр дә бар, аны күңел ачуга санамаучыларны да очратырга мөмкин. Аны күпләр Яңа ел кебек кабул итә. Имеш, экваторны ничек уздырасың, калган уку еллары да шулай үтәчәк. Шуңа күрә әле бу бәйрәмнең тәмен татымаган студентларга берничә киңәш бирәсе килә. Беренчедән, алтын урталыкны таба белегез. Бер көнлек бәйрәм өчен генә төркем эчендәге дуслыкны юкка чыгара күрмәгез. Киңәшләшеп, һәркемнең күңеленә хуш килгән урынны сайларга кирәк! Бәйрәмгә укытучыларны да чакырырга мөмкин. Бу очракта конкурс-ярышлар тагын да кызыграк килеп чыгачак. Имтихан алганда бик кырыс булган укытучыңны бөтенләй башка яктан күрәчәксең. Төрле номинациядә диплом-медальләр тапшыру да бәйрәмгә ямь өстәячәк. Алай гына да түгел, озак еллар бу истәлекле бүләкләрне саклап ләззәтләнергә була. Табынны да мулдан әзерләгез. «Мескен студент» дигән заманнар артта калды бит инде. Дуслар белән җыеласы урынны да матур итеп бизәргә мөмкин. Фантазияңә йоклап ятарга ирек бирмә!

Студент тормышындагы һәр мизгелнең кадерен белергә кирәк, дустым! Бу кыска гына юлның уртасына җитү бик күп әйбер турында сөйли. Димәк, син финишка якынаясың, белем тавының иң биек ноктасына менеп җитәсең. Шуңа күрә күңел ач, ял ит, яңа семестрга көч җый һәм үзең, иптәшләрең өчен истә калырлык бәйрәм кунагы бул!

● Белми калма!

**Аспирантлар, фәнни хезмәткәрләр һәм укытучылар игътибарына!**

***1 февральдә*** *Татарстан Республикасы Җөмһүриятенең «Алгарыш» грантлар программасына* ***гаризалар бирү төгәлләнә****. Тулырак мәгълүмат алу өчен, КФУда әлеге программа кураторы Ольга Павловага мөрәҗәгать итәргә мөмкин.*

***

***3 февральдә*** *КФУда* ***төбәкара фән олимпиадалары старт ала****. Аның катнашучылары булып, 9-11 сыйныф укучылары тора. Олимпиадада теләгән һәр кеше бушка катнаша ала. Олимпиада ике турда үткәрелә. Икенче турда беренче этапта җиңүчеләр көч сынаша.*

***

***Бүген*** *16 сәгать 10 минутта УНИКСның Кече залында FUJITSU* ***уку лабораториясенең презентациясе була****. Мәгълүмати технологияләр һәм системалар югары мәктәбе, Физика институты, Н.И.Лобачевский ис. Математика һәм механика институты, Хисаплау математикасы һәм мәгълүмати технологияләр институты студентлары өчен бу чара аеруча кызык булачак. Биредә FUJITSU компаниясе, лаборатория эшчәнлеге турында тулы мәгълүмат алып булачак.*

Әдәби сәйләннәр

## Авыл төне

**Гөлүсә ШИҺАПОВА,**
Тәрҗемә һәм мәдәниятара
багланышлар бүлеге студенты

*Авылымны томан булып,*
*Сихри төн алды каплап,*
*Алтынсудай сары ай*
*Йокымны тора саклап.*

*Табигать йоклый, тын авыл,*
*Йокламыйм мин берүзем,*
*Тып-тын якты урамга*
*Караган ике күзем.*

*Күк йөзендә ак мендәрләр,*
*Җиремдә ап-ак юрган.*
*Бар дөнья, бар табигать*
*Сихри моң белән тулган.*

*Ә табигать кеше кебек –*
*Юрганда йоклый ул да.*
*Тәмләп йокла, авылым,*
*Тынлыгың минем кулда.*

## Күңел сизә...

**Илмир ВӘЛИЕВ,**
Математика һәм механика
институты студенты

*Дөнья бетә диеп мәш килделәр*
*Яше-карты, бала-чагасы.*
*Күрә алмый калдык иске елда*
*Нинди икән – җәннәт бакчасы?*

*Өмет белән, яңа сулыш белән*
*Йолдызларга таба атладык.*
*Якты күкне, кояш нурын сизеп,*
*Яңа елга кердек шатланып.*

*Тышта хәзер һава каты суык*
*Кинәт кенә буран котыра.*
*Өстән төшкән энҗе*
*бөртекләре*
*Дөньябызны бизәп тик тора.*

*Изгеләрдән изге теләк белән*
*Яңа елга таба атласак,*
*Күңел сизә: могҗизалар киче*
*Яңа елда тагын булачак!*

## Аңламый

**Гөлчәчәк ХӨСНУЛЛИНА,**
татар филологиясе бүлеге
студенты

*Бер әйткәчтен тыңламады,*
*Ике әйттем – кирәк тапмады,*
*Өч кат әйттем – тыңламады,*
*Ә дүрттә аңламады...*

*Бишенчене әйткән идем,*
*Һич тыңлап та тормады.*
*Алтынчыга әйтәм диеп,*
*Йөрәк план кормады.*

*Җиденчегә үзе килде,*
*«Ни диден?» дип сорады.*
*Тагын әйтсәм, сигез була,*
*Акыл шулай уйлады.*

*Тагын кабатла дисә ул,*
*Тугыз була, ярамый.*
*Бер әйтүгә аңламаган,*
*Ун әйтсәң дә аңламый!!!*



Сәламәтлек

# Нәрсә ул «ГМО»?

**Зилә ФӘСХИЕВА,**
хәбәрче

АЗЫК-ТӨЛЕК КИБЕТЛӘРЕНДӘ ЙӨРГӘНДӘ, «ГМО»СЫЗ ДИГӘН ТАМГАЛЫ АШАМЛЫКЛАРГА ИГЪТИБАР ИТКӘНЕГЕЗ БАРДЫР. Ә «ГМО» ЛЫСЫ НИНДИРӘК БУЛА ИКӘН СОҢ? БУ ХАКТА УЙЛАП КАРАГАНЫГЫЗ БАР ИДЕМЕ? ДӘРЕС, РИЗЫКЛАРДАГЫ КҮПЛЕГӘН «Е» ЛАРГА БЕЗ ИНДЕ ИЯЛӘШКӘН, АЛАРНЫҢ КҮПЛЕГЕНӘ, САНЫНА ИГЪТИБАР ДА ИТМИБЕЗ ШИКЕЛЛЕ. ӘММА БЕР ФАКТ БАР: БУ ПРОДУКТЛАР СӘЛАМӘТЛЕККӘ БИК НЫК КУРКЫНЫЧ ТУДЫРА.

ГМО - генетик яктан модификацияләнгән организм, ягъни организмның генотипы ясалма рәвештә үзгәртелгән. Россиядә бүгенге көндә ГМО җитештерү катгый рәвештә тыелган. Шуңа карамастан составында генетик яктан модификацияләнгән организмнар булган продуктларны чит илдән кертү рөхсәтителә. Уйлапкарасак, без ашый торган ризыкның күпчелеге үзебезнең илдә житештерелгән түгел, ә нәкъ менә чит илнеке. Мәктәптә, уку йортларында, күңел ачу үзәкләрендә махсус рәвештә игътибар итеп карасак, бүгенге яшьләрнең кулында Марс, Сникерс, Твикс, Кока-Кола, Спрайт, Фанта һ.б. Саный китсәң күп... Аларның һәркайсында югары дозадагы ГМО катнашмалары бар. Ә нәтиҗәсе бер генә: кешенең организмы нәсел калдыру функциясен югалта.




Беренче тапкыр ГМО 1980 нче еллар тирәсендә кертелә башлый. Безгә кадәрге буынның саулык ягыннан шактый нык һәм гомер озынлыгы артыграк булуы бер дә сәер түгел. Чөнки бу модификацияләнгән организмнар нәтиҗәне кичекмәстән түгел, ә 30-40 елдан соң гына күрсәтәчәк. Тагы бер куркыныч факт бар: галимнәр җир йөзендә яшәүче халык саны киләчәктә шактый артып китәргә мөмкин дигән фикердә. Бу исә ачлыкка, ягъни, халык күп булу сәбәпле, аларны туендырып бетермәү куркынычына китерәчәк дип санала. Ә ГМО продуктлары әкренләп кенә бу ситуацияне хәл итә. Әйткәнемчә, составында «Е» булган продуктлар организмның нәсел калдыра торган вазифасын юкка чыгаралар.

Хәзерге көндә составында аеруча иң күп ГМО булырга мөмкин булган продуктлар: үсемлек майлары, маргарин, майонез, кетчуп, балалар өчен Nestle туклану продуктлары, тундырма, конфет һәм кондитер эшләнмәләре, газлы сулар, шоколад, чипсы, йогурт, тәмләткечләр, төрледән-төрле сагызлар. Азыкның сыйфатыни дәрәҗәдә әһәмиятле булуы аңлашыла да кебек, ләкин практикада онытылып китә шул. Билгеле, аларсыз яшәп булмый һәм булмаячак та, әмма чама дигән хис булырга тиеш.

Уйлап карасак, ярым фабрикатларга караганда өйдә әзерләнгән ашлар күпкә тәмлерәк бит. Ә укудан кайтканда Макдональдска сугылып чыгу гадәтен бөтенләй ташласак иде. Андагы ризыкның 100 % ГМО дан торганы бәлки күпләр өчен яңалыктыр да. Бу очракта әллә ни киңәшләр бирүнең артык мәгънәсе юк та кебек. Бары тик ашаган ризыгыбызга карата сак һәм игътибарлы булырга кирәк!

Студент колагына

# «Бюджетлы» яллар

**Динара ЗИННӘТОВА,**
хәбәрче

АТНАНЫҢ СОҢГЫ КӨННӘРЕН ЗАРЫГЫП КӨТМӘГӘН КЕШЕ БАРМЫ ИКӘН? ШУЛАЙ ДА КҮҢЕЛ АЧАРГА ЯРАТКАН, АКТИВ, ДӘРТЛЕ СТУДЕНТ ХАЛКЫ, ЛЕКЦИЯ ҺӘМ КОНТРОЛЬ ЭШЛӘРЕННӘН АРЫП, ЯЛЛАРНЫ БАРЫСЫННАН ДА НЫГРАК КӨТӘДЕР, МӘГАЕН.

Атна буе «гыйлем ташын» кимергән студент шимбә һәм якшәмбе көннәренә ирекккә ашкынган коштай килеп керә. Әлбәттә, буш вакытны кызыклы, күңелле һәм файдалы итеп үткәрәсе килә. Тик финанс проблемалары студентның бөтен планнарын чәлпәрәмә китерергә мөмкин. Борыныңны салындырырга ашыкма – кесәнең калынлыгына бөтенләй кагылмаган ял итү ысуллары бар. Бүген без сине шуларның берничәсе белән таныштырырбыз.

Аулак өй. Үткән гасыр ич бу, диярсең ашыкма! Әби-бабаларыбыздан килгән әлеге күңел ачу төрен заманча үзгәртү кыен түгел. Иң мөһиме: янында шат күңелле, позитив дусларың булсын. Алар белән җыелышып, кызыклы кичә үткәрегез. Фантазиягезне эшкә җигеп, әлеге чараны аерым темага багышларга була. Крокодил, мафия кебек популяр уеннарны уйнап, аралашып, тәмле чәй артында бик күңелле һәм кызыклы итеп кич утырырга мөмкин.

Экскурсия. Әгәр дә син үзең өчен һәрвакыт нинди дә булса яңа нәрсәләр ачарга яратасың икән, дусларыңны ияртеп, шәһәрнең истәлекле урыннарын урап кайт. Юлыгызны алдан ук билгеләп куеп, әлеге җирләрнең тарихын күзләп чыгыгыз. Бу эштә интернет челтәре – яхшы ярдәмче. Саф һавада йөрү яңа көчләр бирер, өстәвенә, белемегезне дә арттырырсыз. Шик тә юк, мондый экскурсия күңелегездә якты хатирә булып саклачак! Моннан тыш, дусларың белән тагын да якынаеп китәрсең.

Фотосессия. Иң гади фотоаппарат белән дә фото-шедеврлар төшерергә мөмкин. Бигрәк тә фантазияне яхшы эшләтсәң. Телисең икән, гади фотосурәтләр ясарга, теләсәң, иптәшләрең белән нинди дә кызыклы тамаша оештырырга мөмкин. Кичен фотоларны карап, социаль челтәрдәге альбомнарга кертеп, «лайклар» җыеп утыру әлеге чараның күңелле дәвамы булыр. Фотолардан креатив коллаж да төзергә мөмкин. Өстәвенә, студент елларыннан бер матур истәлек тә калачак әле.

Гомумән, дусларыңны урамга ияртеп чыксаң, күңел ачу ысуллары буа буарлык! Балачакны искә алып, чана-чаңгыда шуу, бергәләшеп кар бабае ясау сезне яхшы кәеф, энергия белән тәэмин итәр һәм хәтерегездә якты хатирәләр калдырыр. Сүз уңаеннан, кар бабае ясаганда, примитив өч шар белән генә чикләнмәгез. Кардан аеруча яраткан укытучыгызны яисә үзегез арасыннан берәрсенең сынын ясап карагыз.

Компьютер «коллыгыннан» берәзга булса да аерылып торырга вакыт. Ялларыгыз күңелле үтсен!



DARELFӨNYN УНИВЕРСИТЕТ
Тираж 1000
Газета бушлай таратыла

Баш мөхәррир - Илдар Азат улы Кәримов
Мөхәррир - Динара Равил кызы Миннекаева
Иҗат коллективы: А.Ю.Садыйкова, З.Ф.Фәсхиева
Корректор Р.А.Асылгәрәева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.
Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Карти» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Восстание ур., 60 й.